Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

13 май 2020 ел №376

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2013 елның 11 мартындагы «Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында»гы 286 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 24 апрелендәге 17-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы законы 1 статьясы нигезендә,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2013 елның 11 мартындагы «Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында»гы 286 нчы номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 15 ноябрендәге 252 нче номерлы, 2019 елның 26 июлендәге 309 нчы номерлы, 2020 елның 12 мартындагы 359 нчы номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктта «2.16» саннарын «2.16, 2.17 статьялары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталы»нда (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Багманов И.Р.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов